# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

«Кара һәм төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын җыю, эшкәртү, реализацияләү һәм Татарстан Республикасыннан читкә чыгару кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмә кертү хакында

**1 статья.** «Кара һәм төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын җыю, эшкәртү, реализацияләү һәм Татарстан Республикасыннан читкә чыгару кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелмә басмасы, 2000, № 1(1)) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәне кертергә:

1. Закон исемендә һәм преамбулада «һәм Татарстан Республикасыннан читкә чыгару» дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

2. 3 статьяны төшереп калдырырга.

3. 2 статьяны 3 статья дип санарга.

4. 1 статьяны 2 статья дип санарга, аның исемендә «һәм Татарстан Республикасыннан читкә чыгару» һәм текстында «һәм Татарстан Республикасыннан читкә чыгарган» дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

5. Законга түбәндәге редакциядә яңа 1 нче статья өстәргә:

«1 статья. Әлеге Законның гамәлдә булу чикләре

Әлеге Законда каралган хокук бозулар өчен административ җаваплылык, бу хокук бозулар үзләренең характеры буенча җинаять җаваплылыгына китермәгәндә барлыкка килә.».

6. 4 статьяның текстында «Татарстан Республикасыннан читкә» дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 28 марты
№ 704